**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2023 **Чирмешән авылы** **№ 136**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Түбән Кармалка авыл җирлегендә**
**җирдән файдалану һәм төзелеш**
**кагыйдәләре проекты буенча**
**ачык тыңлаулар үткәрү турында**

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2023 елның 06 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елның 22 декабрендәге №80 карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә **КАРАР КЫЛДЫМ:**

1. Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча кушымталар нигезендә ачык тыңлаулар билгеләргә (I өлеш. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе, II өлеш. Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы (картографик материаллар белән: «Шәһәр төзелеше зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар», «Территорияне куллануның аерым шартлары булган зоналар картасы»), III өлеш. Шәһәр төзелеше регламентлары),

2.Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- ачык тыңлауларны оештыручы - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты;

- халык тыңлауларын үткәрү вакыты - 2023 елның 11 декабрендә 15.00 сәгатьтә.

- үткәрү урыны – түбәндәге адрес буенча урнашкан Түбән Кармалка авыл җирлегенең мәдәният йорты: Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Түбән Кармалка авыл җирлеге, Түбән Кармалка авылы, Ленин урамы, 9 йорт.

- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә ала торган адрес - Татарстан Республикасы, Чирмешән муниципаль районы, Түбән Кармалка авылы, Ленин урамы, 44 йорт, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге башкарма комитеты.

3. Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү, ачык тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркем төзергә түбәндәге составта:

Эшче төркем рәисе - Җамалетдинов Илнур Минсәгыйт улы, Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

Эшче төркем рәисе урынбасары - Вилданов Муса Габделхак улы, Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

Эшче төркем әгъзалары:

Севастьянова Наталья Николаевна – Чирмешән муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;

Җиһаншина Эльвира Бурундай кызы - Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы;

Митякин Александр Федорович - Чирмешән муниципаль районы Түбән Кармалка авыл җирлеге башлыгы;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 2023 елның 28 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Чирмешән муниципаль
районы башлыгы Р.Т. Айбатов